ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 23 ноябрь 2024 ел

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә китүчеләрнең гаилә агъзаларыннан, РФ Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү өчен контракт төзегән гаилә әгъзаларыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар,яктырткычлар,электр товарлары һәм махсуз җиһазлар сатып алу, алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Түбән Якый торак пункты территориясен төзекләндерү (үләннәрне чаптыру,территорияне чистарту һәм чүп-чар җыю хезмәтләре күрсәтү; тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (яңа материал өстәп юлларны профильләү, 8 Март урамындагы юлларга асфальт салу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин